КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 ноябрь г.Казань № 957

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервлау тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 май, 194 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервлау тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 май, 194 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрь, 1196 нчы; 2014 ел, 20 май, 334 нче; 2015 ел, 18 июль, 524 нче; 2019 ел, 1 февраль, 62 нче; 2022 ел, 27 август, 915 нче; 2023 ел, 7 февраль, 112 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен» сүзләрен «инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта татар текстында «инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен» сүзләрен «инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервлау тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 18 май, 194 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 2 ноябрь, 957 нче
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләрдә инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Инвалидларны эшкә кабул итү өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау шартларын һәм процедураларын билгели.

2. Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

эш бирүче – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы, хезмәткәр белән хезмәт мөнәсәбәтләренә кергән юридик зат яисә индивидуаль эшкуар;

социаль яклауга аеруча мохтаҗ түбәндәге гражданнар:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар;

ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затлар;

пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча хезмәт пенсиясенә, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган пенсиягә хокук бирә торган яшь җиткәнгә кадәр биш ел дәвамында);

качаклар һәм мәҗбүри күчеп китүчеләр;

хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары;

балигъ булмаган балалар, инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм күпбалалы ата-аналар;

Чернобыль һәм башка радиация аварияләре һәм һәлакәтләре аркасында радиация йогынтысына дучар гражданнар;

урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге гражданнар;

вәкаләтле органның бәяләмәсе буенча даими карау, ярдәм яки күзәтеп тору кирәк булган затларны караучы гражданнар;

оешма ябылуга яисә физик затлар тарафыннан индивидуаль эшкуарлар сыйфатында эшчәнлеге туктатылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән, бала тууга һәм аны карауга бәйле рәвештә эштә өзеклеге булган хатын-кызлар;

иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән затлар.

## II. Эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау шартлары һәм тәртибе

2.1. Эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау хезмәт базарында бертигез шартларда конкуренциягә сәләтсез булган һәм шуңа бәйле рәвештә эш эзләүдә кыенлыклар кичергән инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан билгеләнә торган эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, 30 һәм аннан күбрәк хезмәткәре булган теләсә нинди оештыру-хокук формаларындагы һәм милек формаларындагы эш бирүчеләрдә башкарыла.

Эш бирүчеләрдә, 60-ТРЗ номерлы Законның 3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән эш бирүчеләрдән тыш, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аеруча туры килә торган эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау гамәлгә ашырыла.

2.2. Эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) юлламасы буенча инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар тарафыннан һөнәри уку яки өстәмә һөнәри белем алу узылган чорга кимендә 15 календарь көнгә гамәлгә ашырыла.

Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана торган эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләре буенча эш урыннары саны эш бирүчеләргә (60-ТРЗ номерлы Законның 3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш), инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота буенча эш урыннары санын исәпкә алып, эш бирүче хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саныннан кимендә биш процент күләмендә билгеләнә һәм эш бирүченең локаль норматив акты белән раслана.

Инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана торган эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләре буенча эш урыннары санын исәпләп чыгарганда, вакланма сан тулы күрсәткечкә кадәр киметеп тәгәрәкләнә. Әгәр эш урыннарының исәпләнгән саны бер берәмлектән кимрәк булса, әлеге күрсәткеч нульгә тигез итеп алына.

Эшләрнең (һөнәрләрнең) резервлана торган аерым төрләре буенча эшкә урнаштырылырга тиешле инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар саны эш бирүче тарафыннан квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан эш бирүче вәкиллекләре һәм филиаллары хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча, үткән квартал өчен хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан чыгып исәпләнә.

Эш бирүчеләр эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында белешмәләр бирелгән локаль норматив актлар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу турыдагы мәгълүматны Министрлык тарафыннан расланган форма буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрә.

Инвалидларга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга хезмәт шартлары, гражданнарның һәр категориясе өчен хезмәт законнарында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, эш бирүчеләр тарафыннан төзелә.

Инвалидларга хезмәт шартлары эш бирүчеләр тарафыннан инвалидның индивидуаль реабилитацияләү яки абилитацияләү программасы нигезендә булдырыла.

2.3. Эш бирүченең инвалидларга һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип теркәлгән гражданнарга эшкә урнашу өчен һөнәри уку яки өстәмә һөнәри белем алу кирәкле вакансияләр булганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге:

инвалид һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип теркәлгән граждан белән һөнәри укуны яки өстәмә һөнәри белем алуны (шул исәптән инвалидның индивидуаль реабилитацияләү яки абилитацияләү программасында бирелгән тәкъдимнамәләрне исәпкә алып) килештерә, инвалид һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ граждан тарафыннан сайлап алынган һөнәр буенча аларның укуын оештыра;

эш бирүчегә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән инвалидны һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип теркәлгән, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең һөнәри укуны яки өстәмә һөнәри белем алуны узу турындагы тәкъдимен кабул иткән гражданны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзүне тәкъдим итә.

2.4. Шартнамәдә һөнәри уку яки өстәмә һөнәри белем алу тәмамланганнан соң инвалидны һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданны эшкә урнаштыру тәртибе һәм сроклары билгеләнә. Шартнамә формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Эш бирүче, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең шартнамә төзү турындагы тәкъдимен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көннән дә соңга калмыйча, шартнамә төзи яисә, шартнамә төзүдән баш тарту сәбәпләрен нигезләп, мәгълүмат җибәрә.

Эш бирүче шартнамә төзегән очракта:

шартнамә төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу турыда мәгълүматны Министрлык тарафыннан расланган форма буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрә;

шартнамәнең шартларын үтәүгә йогынты ясарга мөмкин булган хәлләр турындагы мәгълүматны алар барлыкка килгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрә;

инвалидны һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданны шартнамә нигезендә эшкә урнаштырган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бу турыда мәгълүматны халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрә.

2.5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм эш бирүче арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнгән шартлар һәм сроклар нигезендә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге инвалидны һәм (яки) социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар категориясенә караган гражданны һөнәри укуга яки өстәмә һөнәри белем алуга җибәрә.

Инвалид яки социаль яклауга аеруча мохтаҗ граждан һөнәри укуны яки өстәмә һөнәри белем алуны тәмамлаганнан соң, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге түбәндәгеләргә шартнамәдә билгеләнгән срокта хәбәр итә:

инвалидка яки социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданга – эшкә урнашу өчен эш бирүчегә мөрәҗәгать итү кирәклеге турында;

эш бирүче – инвалидның яки социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданның һөнәри белем алуны яки өстәмә һөнәри белем алуны төгәлләве, аның һөнәр (белгечлек), квалификация алуы турында.

2.6. Эш белән тәэмин итү үзәге эш бирүчеләр тарафыннан эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау бурычларын гамәлгә ашыруны мониторинглау кысаларында:

эш бирүче тарафыннан кабул ителгән эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында белешмәләр бирелгән, эш бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган локаль норматив актларны исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

шартнамәләр кысаларында эш белән тәэмин итү үзәге юлламалары буенча эшкә урнаштырылган инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турындагы мәгълүматны Министрлык тарафыннан билгеләгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка җибәрә;

эш бирүче тарафыннан шартнамәнең шартлары үтәлешен һәм әлеге Тәртиптә каралган мәгълүматның халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрелүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

______________________________